ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 159 от «05» 05 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында социаль найм килешүе буенча торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында социаль найм килешүе буенча торакка мохтаҗ буларак исәпкә алу максатларында гражданнарның торак урыны мәйданы белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен гаиләнең бер әгъзасына кимендә 18 кв.метр итеп билгеләргә.

2. Социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында бер гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасын 18 кв.метр күләмендә билгеләргә.

3. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2008 елның 21 августындагы «Социаль наем һәм дәүләт программалары буенча торак урыны мәйданының исәп нормасын һәм торак урыны мәйданын бирү нормасын билгеләү турында» 678/1 нче карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту буенча җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровны билгеләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

0000010894